УДК 811.512.145'373:811.111

***И.Г. Әхмәтҗанов,***
***А.К. Гәрәева***

# ТАТАР ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕНДӘ ДЕНДРОНИМНАР НИГЕЗЕНДӘ ЯСАЛГАН ТОПОНИМНАР

Статья посвящена сравнительно-сопоставительному анализу географических названий, образованных на основе дендронимов в татарском и английском языках. В частности, в ней рассматриваются вопросы классификации топонимов, определения общих принципов их образования и выявления основных лексико-семантических групп данных наименований в указанных языках. Для этого авторами используются сравнительно-сопоставительный, описательный методы исследования.

**Ключевые слова:** топонимика, топонимия, топонимы, дендронимы, классификация, сравнительно-сопоставительный метод, описательный метод, татарский язык, английский язык.

Мәгълүм булганча, кешелек җәмгыятендә тел, катлаулы һәм шул ук вакытта яхшы оешкан система буларак, төрле вазыйфалар башкара, ләкин иң беренче чиратта ул аралашу һәм мәгълүмат алмашу чарасы санала. Бүгенге көндә Җир шарында кулланыла торган телләрдә, аларның һәрберсе өчен генә хас үзенчәлекләр белән бергә, гомуми сыйфатларның булуы да күзәтелә. Әлеге билгеләрне татар һәм инглиз телләре кебек генетик яктан бер-берсе белән бәйләнмәгән телләрдә дә табарга мөмкин [Хисамова, с. 3].

Аерым телләрдәге уртак күренешләрне өйрәнүне максат итеп куйган типологик тикшеренүләр бүгенге тел белемендә мөһим һәм перспектив юнәлешләрнең берсен тәшкил итә. Алар үзара тугандаш булмаган һәм төрле структурага ия булган, шул исәптән аз өйрәнелгән телләрнең дә материалын җәлеп итеп, гомумлингвистик мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирәләр [Сулейбанова, с. 41; Шайхуллин, с. 233].

Фәнни эшнең актуальлеге нәкъ менә югарыда әйтелгәннәр белән билгеләнә. Аның кысаларында татар һәм инглиз телләрендә дендронимнар нигезендә барлыкка килгән географик атамаларның лексик-семантик үзенчәлекләрен чагыштырма планда өйрәнү һәм шуның нигезендә аларның ясалыш принципларын, төп лексик-семантик төркемнәрен ачыклау максат итеп куелды. Бу үз чиратында «1) атамалар этимологиясен дөрес аңлатырга; 2) бүгенге көндә сирәк яисә бөтенләй кулланылмый торган, топонимик лексикада гына сакланып калган борынгы һәм искергән сүзләрне өйрәнеп, аларның мәгънәләрен торгызырга; 3) географик атамаларның барлыкка килү закончалыкларын

аңлатырга; 4) әлеге атамалар барлыкка килгән чорда халыкның мәдәни үсеш дәрәҗәсен, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирәчәк» [Гарипова, с. 22–23].

Дендронимнар, ягъни агач исемнәре, телнең иң борынгы лексик катламнарын тәшкил итәләр. Шуңа бәйле рәвештә бу сүзләр нигезендә ясалган топонимнарны фәнни яктан өйрәнү зур әһәмияткә ия. Аерым алганда, аларда кешенең табигатьне күзаллавы, аңа мөнәсәбәте һәм шуның белән бергә табигый объектлар, үсемлекләр дөньясы турында бай мәгълүмат чагылыш таба.

Семантик яктан географик атамалар күпкырлы һәм катлаулы күренеш тәшкил итәләр. А.В. Суперанская фикеренчә, топонимның семантикасында атама бирелгән объект, сөйләүченең объектка карата мөнәсәбәте, топонимның нигезен тәшкил иткән апеллятивның мәгънәсе һәм сөйләм вакытында әлеге сүзгә мөнәсәбәттә барлыкка килә торган ассоциацияләр турында мәгълүмат чагылыш таба. Шуңа бәйле рәвештә географик атаманың мәгънәсен аңлау өчен ул кулланылган типик ситуацияләрне белү кирәк [Суперанская, с. 322].

Бүгенге көндә дендронимнар нигезендә барлыкка килгән топонимнар чагыштырма планда башкорт һәм немец телләре материалы нигезендә А.Р. Хисмәтова тарафыннан өйрәнелгән. Галим атамаларның бер төркемнән икенчесенә күчешен (дендроним > гидроним / ороним > ойконим) өйрәнеп, әлеге процессның катлаулы һәм берничә баскычтан торган күренеш тәшкил иткәнлеген ачыклый [Хисматова, с. 12].

Тикшерену кысаларында без бу төр атамаларны түбәндәге төп өч төркемгә аердык:

1. Җир өслегендәге агач-куаклыклар белән капланган мәйданнарның атамалары нигезендә барлыкка килгән топонимнар.

2. Ылыслы агачларның атамалары нигезендә барлыкка килгән топонимнар.

3. Яфраклы агачларның атамалары нигезендә барлыкка килгән топонимнар.

Тикшерену нәтиҗәләреннән күренгәнчә, беренче төркем топонимнар арасында татар телендә *урман*, инглиз телендә *wood* ‘агачлык’, *forest* ‘урман’ һәм *hurst* ‘урман белән капланган калкулык’ апеллятивлары нигезендә барлыкка килгән атамалар еш очрый. Мәсәлән:

а) татар топонимиясендә:

*Урман – Яшел Үзән районындагы поселок;*

*Урманасты – Бөгелмә һәм Лениногорск районнарындагы поселоклар;*

*Урманасты Үтәмеш – Чирмешән районындагы авыл;*

*Урманасты Йорткүл – Спас районындагы авыл;*

*Урман Зәе – Көнчыгыш Кама аръягы төбәгендәге елга;*

*Урман күле – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылында;*

*Урманай – Азнакай районындагы авыл;*

*Урмандәй –Аксубай районындагы авыл;*

*Урман күле – Идел алды, Көнбатыш Кама алды, Көнбатыш Кама аръягы төбәкләрендәге күлләр;*

*Урман Чишмәсе – Көнчыгыш Кама аръягы төбәгендәге елга;*

*Урманчы – Мамадыш районындагы авыл һ.б.;*

б) инглиз топонимиясендә:

*Forest and Frith – Дарем (Durham) шәһәрендәге аучылык хуҗалыгы;*

*Forest Hill with Shotover – Оксфордшир (Oxfordshire) графлыгындагы урман белән капланган калкулык;*

*Woodthorpe – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Hazelwood – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Hurst – Дорсет (Dorset) графлыгындагы шәһәр һ.б.*

Икенче төркем топонимнар татар телендә генә очрыйлар, инглиз теле өчен алар хас түгел. Алар нигездә *нарат* һәм *чыршы* дендронимнары нигезендә барлыкка килгәннәр. Мәсәлән:

*Бикнарат – Биектау районындагы авыл;*

*Ишнарат – Арча районындагы авыл;*

*Нарат – Яшел Үзән районындагы поселок;*

*Наратасты – Сарман һәм Мөслим районнарындагы авыллар;*

*Наратасты урманы – Мөслим районы Наратасты авылы янындагы табигать тыюлыгы;*

*Наратлы – Идел алды төбәгендәге күл;*

*Наратлы – Көнчыгыш Кама аръягы төбәгендәге елга;*

*Наратлы – Әлмәт һәм Бөгелмә районнарындагы авыллар;*

*Наратлык – Арча һәм Биектау районнарындагы авыллар;*

*Наратлыкичү – Минзәлә районындагы авыл;*

*Наратъелга – Чистай районындагы авыл;*

*Югары Наратбаш – Буа районындагы авыл;*

*Түбән Чыршылы – Лениногорск һәм Сарман районнарындагы авыллар;*

*Чыршы – Алабуга һәм Биектау районнарындагы авыллар;*

*Чыршылы – Тукай районындагы авыл;*

*Чыршылы Елга – Балык Бистәсе районындагы авыл;*

*Югары Чыршылы – Лениногорск һәм Сарман районнарындагы авыллар;*

*Яңа Чыршылы – Лениногорск районындагы поселок һ.б.*

Татар һәм инглиз телләрендә яфраклы агачларның атамалары нигезендә барлыкка топонимнар да еш очрый. Татар топонимиясе өчен, нигездә, структураларында *каен, тал* һәм *юкә* дендронимнары урын алган атамалар хас. Мәсәлән:

*Каенлы – Түбән Кама районындагы авыл;*

*Каенлык – Актаныш, Буа һәм Кукмара районнарындагы авыллар;*

*Каенсаз – Мөслим районындагы авыл;*

*Каенсар – Арча, Әтнә, Балтач һәм Кукмара районнарындагы авыллар;*

*Кыр Каентүбә – Актаныш районындагы авыл;*

*Шикәрле Каен – Минзәлә районындагы авыл;*

*Каратал – Кама Тамагы районындагы авыл;*

*Таллыбүләк – Азнакай һәм Бөгелмә районнарындагы авыллар;*

*Таллыкүл – Баулы районындагы авыл;*

*Юкәле – Әлмәт районындагы авыл;*

*Юкәче – Мамадыш районындагы авыл һәм Көнбатыш Идел алды төбәгендәге елга һ.б.*

Әлеге дендронимнар (*birch tree* ‘каен’, *willow tree* ‘тал’, *lime tree, linden* ‘юкә’) нигезендә барлыкка килгән топонимнар инглиз телендә дә теркәлде. Мәсәлән:

*Birchanger – Эссекс (Essex) графлыгындагы шәһәр;*

*Birches – Честер (Cheshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Birchdale – Ланкашир (Lancashire) графлыгындагы торак пункт;*

*Willington – Честер (Cheshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Willey – Шропшир (Stropshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Willenhall – Стаффордшир (Staffordshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Willitoft – Йоркшир (Yorkshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Lindhurst – Ноттингемшир (Nottinghamshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Limehouse – Зур Лондон (Greater London) административ берәмлегендәге торак пункт;*

*Linby – Ноттингемшир (Nottinghamshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Lindale – Камбрия (Cumbria) графлыгындагы шәһәр һ.б.*

Шуның бергә инглиз топонимиясе өчен, татар топонимиясеннән аермалы буларак, *beech tree* ‘бүк агачы’, *elm tree* ‘карама’, *maple tree* ‘өрәңге’, *alder* ‘зирек’, *aspen tree* ‘усак’, *ash tree* ‘корычагач’ һәм *poplar* ‘тирәк’ дендронимнары нигезендә барлыкка килгән топонимнар да хас:

*Beech hill – Беркшир (Berkshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Beech – Стаффордшир (Staffordshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Elm – Кембриджшир (Cambridgeshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Elmton – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Elmsted – Кент (Kent) графлыгындагы торак пункт;*

*Elmore – Глостершир (Gloucestershire) графлыгындагы шәһәр;*

*Mapleton – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Mapperley – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Mappleborough – Уорикшир (Warwickshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Mappleton – Йоркшир (Yorkshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Alderley – Глостершир (Gloucestershire) графлыгындагы шәһәр;*

*Aldershot – Гэмпшир (Hampshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Alderwasley – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы торак пункт;*

*Aspley Heath – Бедфордшир (Bedfordshire) графлыгындагы торак пункт;*

*Aspenden – Хартфордшир (Hertfordshire) графлыгындагы торак пункт;*

*Aspull – Ланкашир (Lancashire) графлыгындагы шәһәр;*

*Ashover – Дербишир (Derbyshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Ashton – Честер (Cheshire) графлыгындагы шәһәр;*

*Ashfield – Саффолк (Suffolk) графлыгындагы шәһәр;*

*Ashcott – Сосерсет (Somerset) графлыгындагы торак пунк;*

*Poplar – Зур Лондон (Greater London) административ берәмлегендәге торак пункт һ.б.*

Йомгаклап әйткәндә, татар һәм инглиз топонимик системаларында аерым үзенчәлекләр белән бергә уртак күренешләр дә күзәтелә. Шуның белән бергә биредә табигатьнең аерылгысыз өлешен тәшкил иткән агачларның әлеге халыкларның көнкүрешендә нинди урын алып торганлыгы да чагылыш таба.

**Әдәбият**

*Гарипова Ф.Г.* Татарская гидронимия (вопросы этногенеза татарского народа по данным гидронимии). Книга первая. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 1998. 572 с.

*Сулейбанова М.У.* Типология словообразовательных систем нахских и иноструктурных языков // Вестник Пятигорского государственного лингвистического университета. 2009. №1. С. 41–45.

*Суперанская А.В.* Что такое топонимика. СПб.: Авалон: Азбука-классика, 2009. 256 с.

*Хисамова В.Н.* Глагольная система татарского и английского языков: сопоставительный анализ в аспекте изучения английского языка на базе родного (татарского) языка (переработанное). Казань: Зур Казан, 2015. 328 с.

*Хисматова А.Р.* Дендронимы в башкирском и немецком языках: дис. … канд. филол. наук. Уфа, 2005. 145 с.

*Шайхуллин Т.А.* Языковая репрезентация отношений между родственниками в русских и арабских паремиях // Вестник ТГГПУ. 2011. № 4(26). С. 233–38.

***Әхмәтҗанов Илдар Габдрәшит улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының*
*Халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чит телләрне*
*өйрәнү кафедрасы доценты*

***Гәрәева Альмира Кадыйр кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының*
*Халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чит телләрне*
*өйрәнү кафедрасы доценты*